# КАРАР

**2025 елның 26 ноябре** **№ 2**

**Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Манзарас авылы торак пунктында 2026 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Манзарс авылы торак пунктында гражданнар җыены хәл итте:

1. 2026 елда Татарстан Республикасы Кукмара районы Манзарас авыл җирлегенең Манзарас авыл территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан, 1 төркем инвалидларыннан; 18 яшькә кадәрге 3 һәм аннан да күбрәк балалары булган күп балалы гаиләләрдән һәм ялгыз аналардан; 80 яшькә җиткән һәм аннан өлкәнрәк затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә ашыгыч хәрби хезмәткә чакырылган затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаиләләре әгъзаларыннан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә хезмәт итүгә контракт имзалаган затлар һәм аларның гаилә әгъзаларынан кала,1000 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә:

- җир асты суларының табигый чыгу урыннарын төзекләндерү (чишмәләр)
- торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын урнаштыру, ремонтлау, тоту;
- тышкы яктырту урам челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар өчен мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясе тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау
- беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү;
- торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү;
- су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су басу манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, ташуны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженер корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау;
- һәйкәлләрне (Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарих һәм мәдәният һәйкәлләре) булмаган) урнаштыру, ремонтлау һәм аларга янәшәдәге территорияне төзекләндерү;

- традицион күмү урыннарын төзекләндерү, ремонт, коймалар урнаштыру;

3. Гражданнар җыенның нәтиҗәләрен мәгълүмат стендларында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында www.pravo.tatarstan.ru адресы буенча урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Манзарас авыл җирлеге башлыгы
урынбасары

Ф.З.Махмутов